**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«_02_» _11_ 2021 ел                    Яр Чаллы                    № _3835_

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «2019-2021 елларга Тукай муниципаль районы авыл яшьләре» район комплексы программасын раслау хакында» 2019 елның 10 январендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» дәүләт программасын раслау хакында» 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 10 январендәге 4 номерлы карары белә расланган «2019-2021 елларга Тукай муниципаль районы авыл яшьләре» программасына 2021 елга «Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесендә финанслау күләмен 80000,00 сум күләмендә арттырып үзгәрешләр кертергә.

2. «2019-2021 елларга Тукай муниципаль районында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү» программасы паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганагы» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганагы | Программаны финанслауның гомуми күләме район җирле бюджеты хисабына 14364787,25 сум тәшкил итә.<br>Шул исәптән гамәлгә ашыру еллары буенча:<br>2019 ел – 3655362,98 сум, шул исәптән «Тукай муниципаль районының яшүсмерләр клубы» муниципаль бюджет учреждениесен агымдагы карап тотуга 3119164,48 сум;<br>2020 ел – 4298487,18 сум, шул исәптән «Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесен агымдагы карап тотуга 3782487,18 сум;<br>2021 ел – 6410937,09 сум, шул исәптән «Тукай |

| | |
|---|---|
| | муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесен агымдагы карап тотуга 4928637,09 сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

3. «2019-2021 елларга Тукай муниципаль районы авыл яшьләре» район программасын гамәлгә ашыру буенча чараларны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

4. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә 3 эш көне эчендә әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин